| | |
|---|---|
| СОВЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.02.2020 Кошман ав. № 3

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15 статьяның 14 абзацындагы «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

46 статьяның 3 пунктындагы «түләүле һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында боерыклар (алгатаба - күрсәтмә) һәм» сүзләренә алмаштырырга;

46 статьяның 5 пунктында «түләүле документлар» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзенә алмаштырырга;

49 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацында «кассалы» сүзен «казначылы» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең http://kushman-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 нче елның 1 нче гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башлык Л.Р.Сафина

Совет Кушманского сельского поселения ... авыл җирлеге Советы